**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

02.12.2021 1358-п

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) (алга таба – Регламент) расларга.

2. Җир ресурсларын саклау бүлегенә (Л.Ф.Вәлиева) югарыда аталган Регламентка ярашлы рәвештә эшләрнең башкарылуын тәэмин итәргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И. Ткачук) әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 16 апрелендәге 497-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 16 апрелендәге 497-п номерлы боерыгы белән расланган Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 1318-п номерлы.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В. Манидичевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 2
декабрендәге 1358-п номерлы
боерыгы белән расланды

## Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламенты (алга таба – Регламент) федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели, түбәндәгеләрдән тыш: ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен ясалма җир кишәрлеге булдыру планлаштырылса, ясалма җир кишәрлеге федераль милектәге су объектында оештырылса, бу су объекты Россия Федерациясенең тиешле субъектлары территориясендә тулысынча урнашкан булса һәм аның су ресурсларыннан файдалану Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъектын эчә торган су белән һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен гамәлгә ашырылса, яки федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы субъектлары территорияләрендә урнашмаган су объектында яки аның бер өлешендә ясалма җир кишәрлеге оештырылса, шулай ук ясалма җир кишәрлеге диңгез порты акваториясендәге су объектында оештырылса.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырган физик затлар, юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләрне Министрлыкка җибәрү өчен почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында «Филармония» тукталышына кадәр килергә:

2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 74, 77 номерлы автобуслар;

6, 8, 12 номерлы троллейбуслар.

метро «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмәләр өчен Министрлыкның җир ресурсларын саклау бүлеге (алга таба – Бүлек): (843) 267-68-36, 264-53-09.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://eco.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат белән түбәндәгечә танышырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал).

Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

федераль милектәге су объектында оештырылган ясалма җир кишәрлеге – федераль милектәге су объектында яки аның бер өлешендә төптәге грунтны юдыру яки таркату юлы белән яисә башка төр технологияләрне кулланып оештырыла торган һәм, эксплуатациягә керткәннән соң, шулай ук җир кишәрлеге дип танылa торган корылма;

су объекты – табигый яисә ясалма сулык, су агымы яисә суның даими яисә вакытлыча җыелып торуы характерлы формаларга һәм су режимы билгеләренә ия булган башка төрле объект;

мөрәҗәгать итүче (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, юридик затлар;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – мөрәҗәгать итүченең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгате (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон). Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре булдыруга рөхсәт бирү.

2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы

аталышы

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре булдыруга рөхсәт бирү (алга таба – ЯҖК булдыруга рөхсәт бирү);

2) ЯҖК булдыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.

2.3.2. ЯҖК булдыруга рөхсәт, ЯҖК булдыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен алып баручы урынбасарының (алга таба – министр урынбасары) яки аның алмаштыра торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар рәвешендә формалаштырыла, гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирү (ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту) гариза һәм документлар килгән көннән башлап 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт күчермәсен бирү мондый рөхсәт бирелгән көннән башлап 7 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) түбәндәгеләрне тапшыра:

1) Әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирү өчен гариза;

2) Әлеге Регламентка 2 нче кушымтага ярашлы рәвештәге форма буенча федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проекты;

3) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Федераль милектәге су объектында ясалма җир кишәрлеген урнаштыру схемасына яисә аның бер өлешенә карата таләпләр һәм ясалма җир кишәрлеген төзү составына һәм эчтәлегенә карата таләпләр раслау турында» 2012 елның 29 июнендәге 198 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать ресурслары министрлыгының 198 номерлы боерыгы) белән расланган таләпләр нигезендә эшләнгән, федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма төзелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасы;

4) РФ Табигать ресурслары министрлыгының 198 номерлы боерыгы белән расланган таләпләргә ярашлы рәвештә әзерләнгән, ясалма җир кишәрлеге оештыруны нигезләү;

5) Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проектын килештерү турында (булган очракта) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан бәяләмәләр;

6) Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проекты буенча (булган очракта) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан кисәтүләр;

7) Килештерү комиссиясенең эш йомгаклары буенча ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проектын килештерү турында документ (булган очракта).

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү Россия Федерациясе гражданины паспортын яисә шәхесен таныклаучы башка документны Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхсән кабул итү барышында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.

2.5.4. Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсендә);

2) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсендә).

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле килештерүләрне дә кертеп, һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләр башкаруны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматларны алудан тыш;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда аталган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

2) Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проектында түбәндәге белешмәләрнең булмавы:

2.1) Күздә тотылган максатчан билгеләнешен, шул исәптән ясалма җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану төрен, төрләрен күрсәтеп, ясалма рәвештә оештырылган җир кишәрлегеннән планлаштырыла торган файдалануга күрсәтү. Проектта урнаштырылуы өчен ясалма җир кишәрлеге оештырыла торган конкрет капиталь төзелеш объекты күрсәтелгән булырга мөмкин;

2.2) Планлаштырыла торган ясалма җир кишәрлегенең урнашу урыны.

3) «Федераль милектә булган су объектларында ясалган ясалма җир кишәрлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарыннан яки җирле үзидарә органнарыннан ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт проекты буенча кисәтүләр булуы әлеге проект дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына килгән көннән башлап бер айдан артмаган срокта килгәндә һәм ясалма җир кишәрлеге оештыру турында гариза тапшыру датасына бетерелмәгәндә, яки мондый проект килештерү комиссиясенең эш йомгаклары буенча килештерелмәгән булса.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләр бетерелгәннән соң, мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән кабат Министрлыкка мөрәҗәгать итә ала. Бу очракта Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Регламентта билгеләнгән тәртип нигезендә башкарыла.

Әлеге пунктта каралмаган нигезләр буенча ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту рөхсәт ителми.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

Гариза кергән көннән бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән

расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;

Министрлык бинасы янәшәсендәге парковкада I, II төркем инвалидлар, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган һәм инвалидларны йөртә торган транспорт чараларын түләүсез урнаштыру (җиһазландырылган парковка урыннары булган очракта) өчен парковканың кимендә ун проценты (ләкин бер урыннан да ким булмаган санда) җиһазландырыла. Парковка урыннарыннан файдаланган өчен түләү алынмый.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы.

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) Министрлык бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин ителүе;

3) Белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган биналарның тиешле санда булуы;

4) Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

5) Электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

6) Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

7) Инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндә-геләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Министрлык сайтыннан алынырга мөмкин.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыру) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынында гамәлгә ашырылмый.

2.15.5. Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

Мөрәҗәгать итүчегә консультация Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә бирелергә мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык сайты базасында оештырылган Интернет-кабул итү системасы ярдәмендә электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин (http://www.eco.tatarstan.ru).

Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүче материалларының комплектлылыгын тикшерү, мөрәҗәгать итүченең материалларын карау;

4) федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт (алга таба – ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт) (ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту) әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) мөрәҗәгать итүчегә ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт күчермәсен җибәрү;

8) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Кирәк булганда, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) кәгазьдә, тапшыру турында белдерү кәгазе белән заказлы почта юлламасы белән, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Министрлыкка гариза тапшыра (җибәрә).

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре теркәлә, гариза почтадан җибәрелгән очракта, – билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итә һәм терки.

гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки (электрон рәвештә);

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

гаризаны һәм документларны карауны оештыру өчен Бүлек җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек җитәкчесенә тапшырылган документлар.

3.3.3. Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тиешле карар кабул итү өчен тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган документлар.

3.4. Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирү (ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту)

3.4.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатен ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтләр бирү өчен документлар карауны исәпкә алу, бирелгән рөхсәтләрне теркәү, рөхсәт бирүдән баш тартуны исәпкә алу журналында (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) терки;

Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формалы рәсми мөрәҗәгать җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган документларны (мәгълүматларны) законнарда билгеләнгән срокта бирә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган документлар (белешмәләр) яисә сорала торган белешмәләр булмавы турында Министрлыкка җибәрелгән белдерү.

3.4.3. Бүлек белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан алынган мәгълүматлар нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, әлеге Регламентның 3.4.8 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече:

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында ике нөсхәдә, 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча хат проекты (алга таба – хат проекты) әзерли һәм аны килештерү өчен документлар белән бергә Бүлек башлыгына җибәрә;

гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ике нөсхәдә, килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән хат проектлары, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.4.4. Бүлек башлыгы хат проектын карый, килештерә һәм документлары белән бергә аны Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы раслаган һәм Идарә башлыгына җибәрелгән хат проекты.

3.4.5. Идарә башлыгы хат проектын карый, килештерә һәм аны, документлар белән бергә, кул кую өчен, министр урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ике нөхсәдә, Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм имза кую өчен министр урынбасарына җибәрелгән хат проекты.

3.4.6. Министр урынбасары ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында ике нөсхәдә хат проектына кул куя һәм аны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында ике нөсхәдә имзаланган һәм документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрелгән хат проекты.

3.4.7. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече:

хатны «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында терки һәм ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хатның беренче нөсхәсен гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә;

хатның икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлык архивына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән хат, аның беренче нөсхәсе – мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә), икенче нөсхәсе Министрлык архивына җибәрелгән.

3.4.8. Бүлек белгече ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта:

ике нөсхәдә ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт әзерли;

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтне килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктчасында билгеләнгән процедуралар беткән вакыттан башлап 15 көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт.

3.4.9. Бүлек башлыгы ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтне карый, килештерә һәм Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән, Идарә башлыгына җибәрелгән ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт.

3.4.10. Идарә башлыгы ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтне карый, килештерә һәм, кул кую өчен, министр урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән, министр урынбасарына юлланган ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт.

3.4.11. Министр урынбасары ясалма җир кишәрлеге оештыруга ике нөсхәдә рөхсәткә кул куя һәм аны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ике нөсхәдә имзаланган ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт.

3.4.12. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече:

Ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтне «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт.

3.4.13. Бүлек белгече:

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирү яисә ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында мәгълүматны Министрлыкның Бердәм бүленгән мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – ББМАС) кертә;

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтнең беренче нөсхәсен гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә;

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтнең икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлык архивына җибәрә.

ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәтнең министр урынбасары имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган күчермәсен гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

ББМАС кертелгән мәгълүмат;

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) һәм Министрлык архивына җибәрелгән ЯҖК оештыруга рөхсәт нөсхәләре;

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрелгән ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт күчермәсе.

3.5. техник хаталарны төзәтү.

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта ярдәмендә җибәрелә.

3.5.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.5.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны башкара һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

- эш башкарылуына;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру вакытлары һәм тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең

хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, әлеге органдагы вазыйфаи затның дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Министрлыкка алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
___________________________________

Кемнән:_________________________

(шәхси эшкуарлар өчен: Ф.И.А.,адресы (почта һәм (яисә) электрон)

___________________________________

юридик затлар өчен: оешма атамасы, адресы (почта һәм (яки) электрон)

Гариза

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеге оештыруга рөхсәт бирү турында

Теркәлү номеры ____________________ «__» ___________ 20__ ел.

_____________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. яки аталышы, оешу-хокук формасы, урнашкан урыны)

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген оештыруга рөхсәт бирүне сорыйм:

_____________________________________________________________________

(су объектының атамасы, дәүләт су реестры мәгълүматлары буенча, су объектының яки аның өлешенең урнашу урыны: елга бассейны, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек)

_____________________________________________________________________

(су объектында ясалма җир кишәрлеген урнаштыру урыны, географик координаталары һәм аның үлчәмнәре)

_____________________________________________________________________

түбәндәге юл белән ясалган:

_____________________________________________________________________

(юдыру, грунт салу яки бүтән технологияләрне кулланып)

һәм эксплуатациягә кертелгәннән соң шулай ук җир кишәрлеге буларак таныла.

түбәндәге максатларда куллану өчен:

(су объектында планлаштырылган ясалма җир кишәрлегенең планлаштырылган максатчан билгеләнеше күрсәтелә)

рөхсәтле файдалану төрләре:

(ясалма оештырылган җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану төрләре күрсәтелә)

су объектында ясалма оештырылган җир кишәрлегенә урнаштырып

(су объектында ясалма җир кишәрлегендә урнаштыру өчен күздә тотылган капиталь төзелеш объектлары, аларның параметрлары күрсәтелә)

Кушымта:
1.
2.
3. Тапшырылган документларның исемлеге ___ биттә, 2 нөсхәдә.
-------------------------------

Гаризада һәм теркәлә торган документларда тапшырылган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын раслыйм.

Җитәкче ____________________________ _____________ ______________
(оешманың аталышы) (имза) (Ф.И.А.)
Мөһер урыны (булган очракта)

__________________
(дата)

Элемтә өчен телефон/факс/E-mail:____________________________________

Федераль милектәге һәм Татарстан
Республикасы территориясендә
урнашкан су объектларында ясалма
җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт
бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75
тел. (843) 267-68-01
факс. (843) 267-68-70
E-mail: eco@tatar.ru

«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары
__________________Фамилия, инициаллар
«_____»_____________20___ ел.

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген оештыруга № _____ рөхсәт

Бирелде: ______________________________________________________________
Юридик адрес: _____________________________________________________
Урнашу урыны: _____________________________________________________
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме, тел.:
__________________________________________

1. Ясалма җир кишәрлеген оештыру планлаштырыла торган су объекты турында белешмәләр:

1.1. __________________________________________________________________
(дәүләт су реестры мәгълүматлары буенча су объектының атамасы күрсәтелә, су объектының яки аның өлешенең урнашу урыны: елга бассейны, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек)

1.2. __________________________________________________________________
(су объектында ясалма җир кишәрлеген урнаштыру урыны, географик координаталары һәм аның үлчәмнәре күрсәтелә)

2. Су объектында ясалма оештырылган җир кишәрлегеннән файдалану максаты һәм төрләре:

2.1. Ясалма оештырылган җир кишәрлегеннән файдалану максаты:
______________________________________________________________________

(ясалма оештырылган җир кишәрлегенең максатчан билгеләнеше күрсәтелә)

2.2. Ясалма оештырылган җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану төрләре:
___________________________________________________________________
(ясалма оештырылган җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану төрләре, конкрет капиталь төзелеш объекты күрсәтелә)

2.3. Аны урнаштыру өчен ясалма җир кишәрлеге оештырыла торган капиталь төзелеш объекты турында белешмәләр*:
___________________________________________________________________
(аны урнаштыру өчен ясалма җир кишәрлеге оештырыла торган конкрет капиталь төзелеш объекты күрсәтелә)

* Әлеге белешмәләр мөрәҗәгать итүченең ихтыярына карап күрсәтелә

3. Ясалма җир кишәрлеге оештырылган урында махсус файдалану шартлары булган зоналарның булу-булмавы:

3.1. ______________________________________________________________
(эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклау, балык хуҗалыгы һәм балык саклау зоналары һ.б.)

4. Ясалма җир кишәрлеге оештырылган урында су объектында урнаштырылган гидротехник һәм башка төр корылмаларның булу-булмавы:

4.1. ______________________________________________________________
(плотиналар, дамбалар, яр ныгыту җайланмалары һ.б. күрсәтелә)

5, Кушымталар:

5.1. Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген урнаштыру схемасы;

5.2. Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген оештыруны нигезләү.

Җир ресурсларын саклау
бүлеге җитәкчесе _______________ Фамилиясе, инициаллары
(имза)

Җаваплы башкаручы,
вазыйфасы _______________ Фамилиясе, инициаллары
(имза)

телефон номеры

Федераль милектәге һәм Татарстан
Республикасы территориясендә
урнашкан су объектларында
ясалма җир кишәрлекләре
оештыруга рөхсәт бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 3
нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы экология һәм
табигать ресурслары министрына
______________________________________
Кемнән:__________________________
(шәхси эшкуарлар өчен:
Ф.И.А.,адресы (почта һәм (яисә) электрон)
________________________________
юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адресы (почта һәм (яки) электрон адресы)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
______________________________________________________________________
*(дәүләт хезмәте атамасы)*
Язылган:________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ________________________________________________
______________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:
1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________
3. ______________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:

e-mail:______________________ адресына электрон документ рәвешендә;

_________________________________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә,

файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

____________________ ______________ (______________________)

(дата) (имза) (Фамилия, исем, ата исеме)

Федераль милектәге һәм Татарстан
Республикасы территориясендә
урнашкан су объектларында ясалма
җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 4 нче
кушымта

Хат үрнәге
(Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы бланкында рәсмиләштерелә)

Мөрәҗәгать итүченең атамасы
Почта адресы

Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында

Әлегесе белән федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектында ясалма җир кишәрлеген оештыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителүе турында мәгълүмат бирәм, түбәндәге нигезләр буенча:

___________________________________________________________________________

(әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә баш тарту нигезләрен санап чыгу)

___________________________________________________________________________

Министр урынбасарының яисә
аны алмаштыручы затның
имзасы____________________Фамилиясе, инициаллары

Җаваплы башкаручының фамилиясе
телефон номеры

Федераль милектәге һәм Татарстан
Республикасы территориясендә урнашкан су
объектларында ясалма җир кишәрлекләре
оештыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 5 нче
кушымта

## Федераль милектәге һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләре оештыруга рөхсәт бирү өчен документларны карауны исәпкә алу, бирелгән рөхсәтләрне, бирүдән баш тартуларны теркәү журналы

| № п/п | Мөрәҗәгать итүченең атамасы | Су объектының яки аның бер өлешенең аталышы | Ясалма җир кишәрлегенең планлаштырылган урнашу урыны | Ясалма җир кишәрле-генең мәйданы (км$^2$) | Ясалма җир кишәрле-генең максатчан билгеләнеше | Гаризаны теркәү датасы, керү номеры | Гаризаны һәм тапшырылган документларны һәм материалларны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар | | | Мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт күчермәсен, баш тартуны (төп нөсхә) җибәрү датасы | Тапшырылган документларны карауны һәм рөхсәт әзерләүне гамәлгә ашыручы җаваплы затның фамилиясе, вазыйфасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Дата | Рөхсәтнең № | Баш тарту № | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1 | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | |
| … | | | | | | | | | | | |
| … | | | | | | | | | | | |
| … | | | | | | | | | | | |

Федераль милектәге һәм Татарстан
Республикасы территориясендә
урнашкан су объектларында
ясалма җир кишәрлекләре
оештыруга рөхсәт бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-23 | Olga.Manidicheva@tatar.ru |
| Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе җитәкчесе | 267-68-30 | Albert.Shubin@tatar.ru |
| Җир ресурсларын саклау бүлеге җитәкчесе | 267-68-36 | L.Mubarakshina@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 267-68-08<br>267-68-70 | eco@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |